**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«08» 08 2022 ел Яр Чаллы № 64

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 1 августындагы 62 номерлы карарына өстәп)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгының “Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында” 2022 елның 1 августындагы 62 номерлы карарына өстәп

## КАРАР БИРӘМ

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Әҗмәкәй авыл җирлегендә мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

4. Билгеләргә:

4.1. халык тыңлауларын үткәрү вакытын:

4.1.1. 2022 елның 14 сентябрендә 13:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Әҗмәкәй авылы, Үзәк ур., 35А;

4.1.2. 2022 елның 14 сентябрендә 14:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Иске Гәрдәле авылы, Үзәк ур., 46Б;

4.1.3. 2022 елның 14 сентябрендә 15:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Яңа Сарайлы авылы, Үзәк ур., 51А;

4.2. Әҗмәкәй авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштырылган материаллар белән танышу вакытын: дүшәмбе – җомга, 9:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр);

4.3. проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес: ТР, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, 203 каб.;

4.4. тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2022 елның 11 августыннан 2022 елның 13 сентябренә кадәр кабул ителә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше секторы мөдире О. А. Никитинага йөкләргә.

Район Башлыгы Ф. М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының
2022 елның 02.08 64 номерлы
карарына кушымта

# ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТАНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Проектның график һәм текст материаллары Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе – җомга, 9:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр).

4. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

5. Проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2022 елның 11 августыннан 2022 елның 13 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 каб.

6. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

7. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

8. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

9. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

10. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

11. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Әҗмәкәй авыл җирлегендә мәгълүмат стендларында урнаштырылырга тиеш.